от 13.02.2023 № 82

БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

«13» 02 2023 ел

№ 82

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының кайбер норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга транспорт чараларын үлчәү һәм габаритлы тикшерүгә кагылышлы өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 20 июлендәге 239-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 5 өлешкә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2023 елның 13 гыйнварындагы 05-51/166 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясында билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә авыр йөк һәм (яисә) зур габаритлы транспорт чарасының автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итүенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. «Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Балтач звеносы турында» 2006 елның 15 мартындагы 65 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. «Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Балтач звеносы турында» 2006 елның 15 мартындагы 65 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 19 февралендәге 69 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарыүз көчен югалткан дип танырга.

4. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең эш регламентын һәм вазыйфаи инструкциясен раслау турында» 2014 елның 3 мартындагы 139 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 6 августындагы 234 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.1. Преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.2. 2.4.1 пунктның 3 абзацында «кырык биш көн» сүзләрен «утыз биш көн» сүзләренә алмаштырырга.

6. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 6 августындагы 233 номерлы карары белән расланган җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең территориядә урнашу схемасын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.1. Преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.2. 2.4.1 пунктның 4 абзацында «кырык биш көн» сүзләрен «утыз биш көн» сүзләренә алмаштырырга.

7. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә шәһәр яны автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 24 октябрендәге 327 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.1. Преамбулада «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидия бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый

актларга гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.2. 1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 18 июнендәге 491 номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.3. 5.1 пункттагы 5 абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 18 июнендәге 491 номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.4. 2 нче кушымтаның 1.1 пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 18 июнендәге 491 номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.5. 3.1 пунктның 10 абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучылар чит ил юридик затлары, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслаган Россия Федерациясендә активларны арадаш (офшор) тоту өчен кулланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган (алга таба - офшор компанияләре), шулай ук устав (туплау) капиталында турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) офшор компанияләренең катнашу өлеше 25 проценттан артып киткән Россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса) булырга тиеш түгел. Офшор компанияләренең россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләгәндә, акцияләре Россия Федерациясендә оештырылган сәүдәләрдә әйләнгән ачык акционер җәмгыятьләре капиталында (шул исәптән халыкара компания статусы белән) офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең әлеге ачык акционер җәмгыятьләре капиталында катнашу аша гамәлгә ашырыла торган башка Россия юридик затлары капиталында турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

8. «Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 186 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

9. «Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 186 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 29 сентябрендәге 287 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

10. «Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 186 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 18 мартындагы 120 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

11. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

12. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов